Республика Татарстан

САБИНСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ ГОРОДСКОЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САБА ШӘҺӘР

БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» май 2025 ел № 194

Саба шәһәр башкарма комитетының 21.10.2022 ел, № 140 “Хезмәт хакын түләү буенча Бердәм тариф челтәренә карамый торган аерым бюджет оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләү шартлары турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 14 апрелендә 226 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфа окладлары күләмен арттыру һәм 30.03.2018 ел, №195 “Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре” карарына үзгәрешләр кертү нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Саба шәһәр башкарма комитеты 21.10.2022 ел, №140 “Хезмәт хакын түләү буенча Бердәм тариф челтәренә карамый торган аерым бюджет оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакын тәләү шартлары турында”гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** карарның 1 пунктындагы дүртенче абзацында «13 990» санын «15 389» санына алыштырырга.

**1.2.** 3 пунктның 3 пунктчасында «37 процент» сүзләрен «52 процент» сүзләренә алмаштырырга;

**1.3.** 4 пунктның бүлегендә «37 процент» сүзләрен «52 процент» сүзләренә алмаштырырга.

**2.** Әлеге карарның гамәлдә булуын 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарату.

**3.** Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы һәм Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/saba адресы буенча бастырып чыгарырга.

Саба шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Р.Г. Гыйлманов